## КИҢӘШЛЕ КҮПЕР

Рөстәм Миңнеханов белән Марат Хөснуллин яшьләргә нәсыйхәт бирде

> 2

## РӘХМӘТ, ТАБИБ!

Бала чагыннан инженер булырга хыялланган егет ни өчен табиб һөнәрен сайлаган?

> 3

## МАТУР УРАМ

Республикада 2023 елда төзекләндереләчәк җәмәгать урыннары һәм ишегаллары өчен тавыш бирү башланды

> 4

## КЫРЛАЙ КУЛИБИНЫ

Өендәге кабак турагыч, иттарткыч, мамык ясаучы җайланма да – аның хезмәте

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 55 (28828) | Сишәмбе | 19 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# АЙГАМЫ, БЕР КӨНГӘМЕ?

**Бәяләр төшә! Яңа атна шундый яңалыктан башланды. Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, бер атна эчендә кибетләрдә кайбер төр продуктлар, көнкүреш техникасы очсызланган. Илдә яңа һәм тотылган машина бәяләрендә дә үзгәреш сизелә башлаган. Вакытлы күренешме бу? Алга таба бәяләрдән ни көтәргә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.**

Көнкүреш техникасы сатучы билгеле кибетләр бу көннәрдә акциядә катнашучы товарлар санын арттырган. Нәтиҗәдә товарлар уртача 10–30 процентка, кайберләре хәтта 50 процентка ук очсызланган. Моны күпләр үз итеп өлгергән «Ozon»да да раслыйдылар. Аерым алганда, соңгы бер атнада ноутбук һәм планшетлар – 22, көнкүреш техникасы 15 процентка арзанайган.

«ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән DNS көнкүреш техникасы кибетендә биредәге бәяләр моннан да ары арзанаймас дип саныйлар. Консультант егет Руслан Гыйльметдинов сүзләреннән аңлашылганча, бүген биредә, дөрестән дә, күп кенә көнкүреш техникасы очсызланган. Телевизорлар исә, киресенчә, кыйммәтләнгән. «Атна башында Үзәк банк төп ставканы төшергәч, бездә суыткыч, кер юу машиналары, компьютерларның бәясе төште. Дөрес, барлык төрләренеке дә түгел. Әйтик, Кореяда җитештерелгәннәренең хакы үзгәрешсез калды. Соңгы арада бездә телевизорлар кыйммәтләнде. Кореядан азрак кайтарылгач, аларга дефицит барлыкка килде», – ди ул. Руслан сөйләгәннәрдән аңлашылганча, соңгы арада кибетләрдә кайбер төр смартфоннар да очсызланган. Әмма алар башка арзанаймас дип фаразлый егет. «Хәзер бездә бик күп кенә брендлар сатылмый башлады. Шуңа күрә Кытайда җитештерелгән смартфоннарга сорау артачак. Бу – аның бәясе дә күтәреләчәк дигән сүз», – ди ул.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов көнкүреш техникасына бәяләр төшә башлауның берничә сәбәбен атый. Белгеч фикеренчә, сатучылар әле бер ай элек кенә кибетләрдә күзәтелгән ажиотаж вакытында булган барлык товар запасын сатып бетерергә өлгермәгән. «Аларның складларында әле дә элеккеге бәядән сатып алынган товарлар бар. Бу товарларга сорау кимегәнлектән, сатучылар бәяләрне төшерергә мәҗбүр», – ди ул.

Фәнис Хөсәенов килеп туган вазгыятьтә бер мөһим кагыйдәне истән чыгармаска чакыра. Кризис башланганчы кирәкле әйберегезне алып өлгермәгән булсагыз, сабыр итәргә кирәк. Белгеч, Үзәк банк төп ставканы алга таба да төшерәчәк, дип фаразлый. Бу бәяләргә дә йогынты ясаячак. Шул рәвешле, әйтик, шул ук көнкүреш техникасын сатып алу әлегә көченнән килмәгән кешеләр моны ел азагында эшли алачак.

– Күп кенә оешмалар безнең базардан китсә дә, теге яки бу товар сатуда булмас дип борчылырга кирәкми. Күптән түгел безнең илдә параллель импорт турында закон кабул ителде. Аның нигезендә шушы ук товарларны өченче – арадашчы илләр аша сатып алу рөхсәт ителә. Хәзерге вакытта Россиянең Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы тарафыннан әлеге товарлар исемлеге төзелә. Шуңа күрә без алырга күнеккән товарлар кибет киштәсендә, һәрхәлдә, булачак. Алар кыйммәтрәк булырмы-юкмы – монысын әлегә фаразлавы кыен, – ди Фәнис Хөсәенов. – Товарны турыдан-туры кайтарту авырлашкач, безнең илгә кергән импорт товарлар саны беренче чорда азрак булачак. Шуңа күрә ел дәвамында көнкүреш техникасы, аларга сорау зур булудан бигрәк, аз санда булуы аркасында кыйммәтләнергә мөмкин. Безнең базарга җитәрлек күләмдә товар кайтарылсын өчен, уртача бер ел чамасы вакыт кирәк булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

### «Тимер ат» та арзаная

Фәнис Хөсәенов кибеттәге азык-төлек бәяләре дә акрынлап киму ягына барачак дип фаразлый. Бу көннәрдә кибетләрдә кайбер төр продуктлар очсызланган инде. Әйтик, берничә атна элек килограммы 125 сумнан (!) сатылган кәбестә бу көннәрдә 40 процентка арзанайган. Баклажан һәм киви (50 процент), ташкабак (42,5 процент), груша белән кыяр бәясе дә төшкән. Күптән түгел белгечләр кибетләрне йөреп чыккан. «Ашан» кибетләр челтәрендәге бәяләр аларны бигрәк тә гаҗәпкә калдырган. Әйтик, биредә кайбер төр товарлар җиде тапкыр (!) арзанайган. Белгечләр иң арзан он, ипи, кишер, суган нәкъ менә биредә сатыла дигән нәтиҗәгә килгән. Моннан тыш, алар «Магнит» кибетләрендә – карабодай, бәрәңге, сөт һәм чәй, «Перекресток» кибетендә йомырка, тоз, дөге очсызланганын ачыклаган.

– Билгеле булганча, март аенда азык-төлек бәяләре коточкыч дәрәҗәдә үсте. Сатучылар, кибетләрдәге ажиотаждан файдаланып, киштәдәге товар хакларын күтәрә торды. Үзәк банк кулланган алымнар нәтиҗәсен бирде. Беренчедән, ул төп ставканы 20 процентка кадәр күтәрде. Бу паникага бирелгән кеше, булган акчасыннан тыш, кредит акчасын да тотып бетермәсен өчен эшләнде. Шул рәвешле кредит бәясе бик нык үсте. Бу исә, үз чиратында, ажиотаж дәрәҗәсендәге сорауның кимүенә китерде. Нәтиҗәдә күреп торабыз: әле кайчан гына бер кило шикәр комының хакы 100 сумнан артып киткән булса, хәзер аны уртача 60 сумга алырга мөмкин. Көзгә таба ул тагын да арзанаер дип уйлыйм, – ди белгеч.

Билгеле булганча, быелның 30 июненә кадәр бездә читкә бодай чыгару тыелган. «Бу шулай ук азык-төлек бәяләренең кими башлавына китерде. Алар алга таба да акрынлап арзанаячак. Әмма бәяләрнең күпмегә төшәчәген фаразлау кыен. Ник дигәндә, безнең илнең мондый ук җитди санкцияләр чолганышында калганы юк иде әле. Вазгыятьнең нинди булачагы якынча июнь урталарында гына ачыкланачак», – ди Фәнис Хөсәенов.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә Россиядә машиналар да очсызлана башлаган икән дигән хәбәрләр таралды. «Авто.ру» аналитик үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, ике атна элек Россиядә тотылган машиналар 20–40 процентка арзанайган. Ник дигәндә, аларга сорау бик нык кимегән. Белгечләр автосалондагы яңа машина бәяләре дә төшә башлаган дип ышандыра. «Автостат» аналитик үзәге белгече Сергей Целиков, бу очракта сөенергә иртәрәк, ди. «Сумның тотрыклануы аркасында алдагы ике-өч ай дәвамында яңа машина бәяләре төшәчәк әле. Әмма шулай да «тимер ат» хаклары ел башындагы дәрәҗәдә булмаячак», – ди ул.

## Табиблар хастаханәгә кайта

Татарстанда 8 меңнән артыграк медицина хезмәткәре гадәттәге эш урыннарына кайткан. Коронавирусның берникадәр сүлпәнәюенә бәйле бу. 2020 елда, пандемия башлангач, республикада 16,6 мең табиб һәм шәфкать туташы, «ашыгыч ярдәм» машинасын йөртүче 936 кеше чир йоктыручыларга медицина ярдәме күрсәтүгә җәлеп ителгән. Узган елда вакытлыча госпитальләрдә эшләүче медицина хезмәткәрләре саны 18,5 меңгә җиткән, ә йөртүчеләр, берникадәр кимеп, 887гә калган.

Хәзерге вакытта республикада COVID-19 инфекциясеннән барлыгы 10420 табиб дәвалый, «ашыгыч ярдәм» машинасын йөртүче 223 кеше мондый сырхауларга хезмәт күрсәтә.

Белүебезчә, апрель башында Россия Премьер-министры Михаил Мишустин ил төбәкләренә планлы медицина ярдәмен тулы күләмендә торгызырга кушты. Аның әйтүенчә, узган елда 50 миллионга якын кешегә диспансеризация үткәрелгән. Шуның якынча 2 миллионы ковидтан соң тирәнтен медицина тикшерүе узган.

Тик коронавирус барыбер китәргә бик җыенып тормый әле. Соңгы тәүлектә Татарстанда чир йоктыруның 245 яңа очрагы теркәлгән. 34 кеше хастаханәгә салынган. Соңгы мәгълүматларга караганда, пандемия башланганнан бирле республикада барлыгы 141862 кеше ковид кичергән. Җәмгысы 1946 сырхау вафат булган. Шуның дүртесе – соңгы тәүлектә.

## *Базар үзе киләчәк*

Россия Хөкүмәте азык-төлекне күпләп сату базарларын үстерүне планлаштыра. Авыл хуҗалыгында товар җитештерүчеләрне зур шәһәрләрдә сатып алучыларга якынайту максатына бәйле бу.

Премьер-министр Михаил Мишустин әйтүенчә, мондый базарлар халыкны сыйфатлы, чагыштырмача арзан азык-төлек белән тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк. «Аларда, күпләп сатудан тыш, ваклап сату өчен дә шартлар тудырылачак. Димәк, кешеләр кайдан сатып алуның үзләре өчен отышлырак һәм уңайлырак буласын аңлап-белеп торачак», – дигән Михаил Мишустин.

Моңа кадәр Россия Президенты Владимир Путин «буй җитәрлек» бәядән сыйфатлы азык-төлек җитештерү күләмен арттыруны төп бурыч итеп куйды. Күпләп сату базарларын үстерү товар җитештерүчеләргә продукциясен сату өчен туры юл ачып, аларның чыгымнарын киметүне, димәк, бәяләрне дә арзанайтуны күздә тота.

## Безне якын күрәләр

Татарстан чит илләрдән килүчеләр иң нык якын иткән төбәкләрнең берсе санала. Россия Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары шуны раслый. Мигрантлар саны буенча безнең республика Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан, Мәскәү, Ленинград, Свердловск, Иркутск, Самара, Новосибирск өлкәләреннән, Краснодар, Приморье, Красноярск крайларыннан гына калыша.

ТАСС хәбәренә караганда, Россиядә теркәлгән мигрантлар саны пандемиягә кадәрге чордагы күрсәткечкә якынлашкан. Агымдагы елның ике аенда чит илдән килүчеләр саны узган елның шушы ук чорындагыга караганда 2,5 тапкыр күбрәк булган. Аларның эшчәнлеге үзгәрешсез диярлек калган. Шул ук вакытта эшләү өчен бирелгән патентлар саны ике тапкырдан күбрәккә артып, 271,6 меңгә җиткән (узган елның шушы чорында – 112 мең). Украинада махсус хәрби операция башлангач, Россиягә Украинадан, Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан күпләп килә башлаганнар.

## *Укуның да ярдәме булачак*

«Бердәм Россия»нең Татарстандагы бүлеге «Донбасска – китаплар» гомумроссия акциясен хуплап, аларга дәреслекләр, балалар һәм үсмерләр өчен нәфис әдәбият, энциклопедияләр юллаган. Шулай итеп, партия бүлеге күпне күргән төбәккә барлыгы 5 меңнән артыграк китап җибәргән.

Халык инициативаларын хуплау буенча төбәк үзәге координаторы Ксения Дромняк әйтүенчә, әлеге чараны уздыру фикере Донецк һәм Луганск халык республикалары вәкилләре белән Дәүләт Думасында узган очрашудан соң барлыкка килгән. «Акциянең максаты Донбасс балаларына алар өчен гадәти булган рус теле мохитендә уку, үсү мөмкинлеген кире кайтарудан гыйбарәт. Татарстан акциягә бик теләп кушылды. Безгә төрледән-төрле китаплар китерделәр. Аларның күпчелеген ДНР һәм ЛНР балаларына җибәрәбез. Ә бер өлешен авыл китапханәләренә һәм ДРКБ китапханәсенә тапшырачакбыз», – дигән ул.

**Һава торышы**

# Куанырга иртәрәк: яз озак килә

**Ниһаять, кояшлы матур язлар җитте дигәндә генә, бозылды да куйды көннәр. Ялларда ап-як кар явып «куандырса», дүшәмбе суытып та җибәрде. Синоптиклар сүзләренә карасак, алдагы көннәрдә дә юеш, тотрыксыз һәм салкын һава сакланачак. Карлы яңгырлары да булачак. Һава температурасы төнлә –2...+3 градус булса, көндезләрен +6...+11 градус тирәсендә тирбәлер, ди белгечләр.**

20 апрельдә төнлә яңгыр, Татарстанның төньягында җепшек кар явачак. Көндез урыны-урыны белән яңгырлар көтелә. 21 апрельдә исә республикада коры һава торышы сакланачак.

Машина йөртүчеләрнең күпчелеге тәгәрмәчләрен җәйгегә алыштырырга да өлгергән иде инде. Шуңа күрә Татарстан Эчке эшләр министрлыгының дәүләт автоинспекциясе бу көннәрдә аеруча сак булырга кирәклеген искәртә. Кар һәм яңгыр яву, салкын һава торышы юлларда бозлавык хасил итәргә мөмкин. Җитмәсә, томаны да булачак.

– Бу көннәрдә юлларда тагын да саграк булырга кирәк, – дип кисәтә дәүләт автоинспекциясенең матбугат үзәге. – Куркынычсызлык каешларын да тагарга онытмагыз. Алгы утыргычка – 12, арткысына 7 яшькә кадәрге балаларны махсус җайланма белән генә утырту рөхсәт ителә.

Кукмара районының Кәчимир авылында яшәүче халык синоптигы Салих Шәрипов әйтүенчә, апрельнең калган көннәре дә кояшлы һава торышы белән артык шатландырмаячак.

– Җәен бер айдан артык корылык булырга охшап тора. Июньдә яңгырлар яумаячак, – дип фаразлый халык синоптигы. – Апрель өчен мондый һава торышы – гадәти күренеш, әллә ни гаҗәпләнәсе түгел. Яз соңга калып килде. Элек тә апрель урталарында чана җигеп йөрерлек кар ява торган иде. Тик апрель кары бик тиз эрүчән. 1959 елда кыш суык булды, ләкин ташуы соңга калган иде. Быел, кар көпшәк булганлыктан, тиз эреп бетте.

Салих Шәрипов фикеренчә, майда да җылы көннәр күп булмас төсле.

**Сүзгә-сүз**

rg.ru

**Ольга ВАСИЛЬЕВА, Россия Мәгариф академиясе президенты:**

Минемчә, без соңгы елларда сәләтле балаларга зур игътибар бирү белән мавыгып киттек. Беркемне дә төшереп калдырырга ярамый, чөнки башкаларны күз уңыннан ычкындыруның ахыры бик тә аянычлы булырга мөмкин.

**(Халыкара ассамблеяда ясаган чыгышыннан)**

## РОССИЯДӘ – КРЕДИТ БУРЫЧЫ

**«РИА Рейтинг» оешмасы төбәкләрдә халыкның кредит бурычын ничек каплавын ачыклаган.**

| | Төбәк | Вакытында түләнмәгән кредит өлеше (%) | Уртача кредит суммасы (мең сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | Севастополь | 1,87 | 126 |
| 2 | Ненец АО | 1,98 | 463 |
| 3 | Ямал-Ненец АО | 2,08 | 634 |
| 4 | Кырым | 2,55 | 99 |
| ... | | | |
| **12** | **ТАТАРСТАН** | **-0,31** | **352** |
| ... | | | |
| 82 | Адыгея р. | 6,21 | 300 |
| 83 | Карачай-Черкесс р. | 6,57 | 227 |
| 84 | Төньяк Осетия р. | 6,86 | 241 |
| 85 | Ингушетия р. | 8,86 | 39 |
| | **РФ** | **3,85** | **333** |

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## КӨРӘШ КЫЗА БАРА

Планетаның төрле почмакларында сәяси атмосфера кыза һәм катлаулана. Дүшәмбе иртәсенең төп яңалыгы итеп, Йәмән президенты Мансур Һадиның үз вәкаләтләрен «Президент идарәче советы» дигән оешмага тапшыруы тәкъдим ителде, мәсәлән. Ул хәзер йорт сагы астында утыра. Түнтәрелгән президент бу адымга Согуд Гарәбстаны басымы нәтиҗәсендә барды. Әр-Риядта сөйләшүләр вакытында принц Мөхәммәд бән Сәлмән аның кулына «язма указ» тоттырды да, Йәмән лидеры отставкага китәргә мәҗбүр булды. Түнтәрелеш алдыннан гына Әр-Риядның тәхет варисы Владимир Путин белән телефоннан сөйләште. Сөйләшүдә Украина тирәсендәге вазгыять, Йәмән конфликты һәм ОПЕК+ кысасындагы эшләр тикшерелде. Беренче карашка гарәпләрнең – Украина кризисына, Россиянең Йәмән конфликтына бернинди дә катнашы юк шикелле. Әйтик, Мәскәүнең Йәмән гыйсъянчыларына басым ясау мөмкинлеге, Әр-Риядның Зеленскийга йогынтысы нульгә тигез дип әйтерлек. Әмма Россия Иранга – гыйсъянчыларның төп спонсорына үтенеч белән мөрәҗәгать итә ала, ә Согуд Корольлеге – нефть чыгаруны контрольдә тотучы төп көч. Вашингтон күпме генә тырышса да, гарәпләрне нефть чыгаруны арттырырга мәҗбүр итә алмады. Россия Иран аша Йәмән гыйсъянчыларына йогынты ясый алса һәм согудләрнең көньяк чигендә вакытлыча гына булса да тынычлык урнашса, гарәпләр, бу яхшылыкка җавап итеп, нефть кранын кысып тора ала. Бу очракта Көнбатыш санкцияләре Россия өчен артык зур куркынычка ия түгел. Кыска сроклы перспективада дип әйтик инде, чөнки вакытлар узган саен, чикләүләрнең катылыгын тоячакбыз барыбер.

Дүшәмбе иртәсенең тагын бер мөһим яңалыгы: Төркия Гыйракның төньягында көрд фетнәчеләренә каршы яңа хәрби операция башлады. Гыйрак бездән еракта дип тынычланып булмый бу очракта да. Вакыйга менә бу юлларны язып утыручыга (һәм аны укучыларга да) читләтеп булса да кагыла. Игътибар итегез: төрек хәрби операциясен халыкара җәмәгатьчелек бер дә гаепләми. Төрек оппозициясе генә моңа каршы чыкты. Әрдоган һөҗүм алдыннан Гыйрак Көрдстаны премьер-министры Мәсрур Барзани белән очрашып сөйләште. Очрашуда төрек милли разведкасы MIT җитәкчесе Хакан Фидан да бар иде. Бу үзе үк инде хәрби операция әзерләнү турында сигнал булды. Көрд автономиясенең рәсми лидерлары үз җирләрендә күрше дәүләтнең сугыш алып баруына каршы түгел, хәтта аны яклыйлар да. Гыйрак Көрдстаны – газ ятмаларына бик бай төбәк, алар үз газларын Төркия аша Европага илтергә телиләр. Моның өчен гыйсъянчыларны басып, төбәктә тынычлык урнаштырырга кирәк. Көрдстан газы Көнбатышка агыла башласа, безнең кесәләр моның тискәре нәтиҗәсен тоймый калмаячак. Аңлыйсызмы төрек хәрби операциясенең безгә ничек кагылуын? Менә шул шул. Планета артык кечкенә, базарлар бер-берсенә артык якын һәм Җир шарының әллә кайсы почмакларында барган вакыйгалар да безгә кайтаваз бирә. Пакьстанның яңа гына түнтәрелгән премьер-министры Имран Хан: «Россия безгә нефтьне һәм бодайны утыз процентка арзангарак бирергә килешкән иде», – дигән белдерү ясады. Исламабадта парламентның бер карары безне зур базардан мәхрүм иткән булып чыга. Хәер, Пакьстанның яңа премьеры да арзанлы нефтькә һәм бодайга каршы килмәстер, мөгаен.

**Россиядә**

## ТӘРТӘЛӘРНЕ КӨНЧЫГЫШКА БОРГАНДА

Углеводородлар сатуның Россия өчен никадәрле әһәмиятле булуын төшенәсездер. Нефть, газ һәм ташкүмер – безнең бюджетыбыз, пенсияләребез, базарларыбызның муллыгы ул бүген. Безне шулардан мәхрүм итү өчен тиңсез көрәш бара. «Российская газета»ның «Телеграм» каналы дүшәмбе иртәсендә күңелсез бер хәбәр урнаштырды. «Көнбатышның акрынлап Россия углеводородларыннан баш тартуы бара инде. Әгәр ул тизләнсә, Көнбатышка илткән күләмнәрне Көнчыгышка таба бору барып чыкмаячак», – дип язды. Дөрес, газета Азия – Тын океан төбәгенә экспортны арттыру өчен, инфраструктураны киңәйтергә кирәк дигән нәтиҗә ясый. Әмма «киңәйтү» дигәне бик җиңел генә эш түгел. Бу юлларны язар алдыннан гына «Совкомфлот»ның Кипрдагы кече компаниясен ябарга мәҗбүр булуы турында хәбәр килеп төште. Сәбәбе аңлашыла торгандыр инде: Европа портлары Россия кораблары өчен бикләнәләр. Башка санкцияләр дә бугаздан кыса. «Совкомфлот» исә – Aframax классындагы 110 танкерга ия булган дөньядагы иң эре компанияләрнең берсе. Хәзер аңа Азия дәүләтләренең берсендә теркәлергә кирәк булачак. Әлегә Вашингтон җитәкләгән Көнбатыш коалициясе, Кытай, Һиндстан, Көньяк Африка республикасы, Бразилия кебек гигантларны үзенә буйсындырып, бердәм санкцияләр кыршавына куып кертә алмады. Өченче дөнья илләре – африкалылар һәм азиатлар, Латин Америкасы Көнбатышның уен кагыйдәләрен кабул итми. Бу Россияне яратканлыктан түгел, билгеле, икътисади вазгыять аларны Мәскәү белән хезмәттәшлек итәргә мәҗбүрили. Арзанлы чимал кызыктыра. Әйтик, Һиндстан март аенда рекордлы күләмдә Россия ташкүмерен сатып алган.

Вашингтон дипломатиясе актив эшли бүген. Россияне тимер кыршау эченә алу өчен көрәш дәвам итә. Әлегә бу юнәлештә тулы уңышка ирешә алмаган көнбатышлылар этлек эшләүнең яңа ысулларын эзли. Италия премьер-министры Марио Драги Россиянең табигый газына бәя түшәме куярга чакырды. Әле кайчан гына итальяннар Россиянең аркадашлары иде, бүген Мәскәүгә актив рәвештә аяк чалалар. Италия тәкъдиме яклау тапты һәм Европа Советының киләсе утырышында каралачак. Европа сәясәтчеләре, бу ысул белән Россияне финанслауны киметәбез, дип әйтәләр. Базар шартларында бу ничек тормышка ашырылыр, әйтү кыен. Бер нәрсә ачык: газ агымын тиз генә туктатып булмаячак. Болай да апрель аенда бик күп санда нефть скважиналары томаланган инде, «кара алтын» чыгару күләме нык кимегән. Газ белән эш тагын да катлаулырак. Белгечләр әйтүенчә, Азия – Тын океан төбәгенә борылыш ясау мөмкин, әмма катлаулы. Финанслар белән идарә итүнең югары мәктәбе белгече Михаил Коган торба сузу өчен еллар кирәк булачагын әйтә. Күп акча түгеп, торбалар сузган очракта да Россия газына бәя түшәмен азиатлар куймас дип кем әйтә ала?

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

# МӘСКӘҮДӘН ЯХШЫРАК КҮРЕНӘ

**Киңәш беркемгә дә комачау итми. «Мәскәү – Татарстан күпере» яшьләр форумында да киңәшләрне муллан өләштеләр. Яшьләр белән сөйләшергә сәясәттә, иҗтимагый тормышта, мәдәнияттә һәм башка тармакларда уңышка ирешкән шәхесләр килде. Алар арасында, гадәттәгечә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бар иде.**

tatarstan.ru

Татарстан кебек зур республиканың җитәкчесе нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Ни өчен өлкән иптәшләрнең киңәшенә колак салырга кирәк? Һөнәри үсеш шәхеснең үзенә генә бәйлеме? Рөстәм Миңнеханов форумда катнашучыларга шул хакта сөйләде.

– Бу форум – Мәскәү белән Татарстан арасындагы элемтәләрне ныгыту өчен яхшы мәйданчык. Хәзерге вакытта Татарстаннан чыккан кешеләр федераль дәрәҗәдәге вазыйфаларны били. Бу инде безнең республиканың көче турында сөйли, – диде республика Президенты.

Уңыш сере турында сөйләгәндә, Татарстан Президенты әйтүенчә, һөнәр баскычыннан менгәндә, сиңа ышанган кешеләрнең булуы да мөһим. Ә республика җитәкчесенең бу яктан бәхете бар. «Өлкән иптәшләрем мине һәрчак аңлады һәм ярдәм итте. Ниндидер очракларда хаталарым да булгандыр. Әмма минем белән бергә эшләгән кешеләр мине гел хуплап торды. Моның кадерен белергә кирәк», – диде ул. Шул җәһәттән тиңсез тәҗрибә өчен Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә рәхмәтле булуын әйтте.

Рөстәм Миңнехановка залда утырган яшьләрдән дә сораулар булды. Аның берсе республика җитәкчесенә хас сыйфатлар турында иде. «Республиканың ике дәүләт телен – русча һәм татарчаны камил белергә кирәк», – дип җавап бирде Рөстәм Миңнеханов.

Форумда чыгыш ясаучылар арасында Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин да бар иде. Ул очрашуга килгән яшьләргә шәхси киңәшләрен дә бирде, илнең хәзерге хәлен дә аңлатты.

– Безнең ил бик катлаулы вазгыять кичерә. Безгә каршы чын икътисади һәм мәгълүмати һөҗүм алып барыла. Моңа аеруча игътибар итүегезне сорыйм. Безнең ил турында нидер ишетәсез икән, барысын да үлчәсәгез, бәяләсәгез иде, – диде ул. – Үзегезне күрсәтер, сәләтләрегезне ачар өчен кулай вакыт. Иң катлаулы чорларда иң даһи кешеләр барлыкка килгән.

Башка катнашучылар да киңәшләргә саран булмады. Татарстанның яшьләр эшләре министры булып торган, хәзерге вакытта «Росмолодежь» агентлыгы башлыгы урынбасары вазыйфасын биләгән Дамир Фәттахов исә яңа урынга күчкәч тә якташларның ярдәмен тоюның әһәмияте турында сөйләде. Биатлон буенча Олимпия чемпионы Светлана Ишмуратова тән саулыгын кайгыртуны сорады. Космонавт Сергей Рыжиков мәрхәмәтле, киң күңелле булырга өндәде.

Форумда катнашучыларны видеоэлемтә аша Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев сәламләде. Ул билгеләп үткәнчә, «Мәскәү – Татарстан күпере» буыннар арасында диалогны ныгытуда мөһим роль уйный. «Элегрәк – Татарстан Президенты булган вакытта да, хәзер дә безнең егетләр һәм кызларның уңышларын күзәтеп барам. Татарлар гына түгел, безнең республика белән бәйле барлык кешеләрнекен. Сез бөтен дөнья буенча уңышларга ирешәсез, татар милләтен, күпмилләтле Татарстаныбызны дөньяга танытасыз», – диде ул.

Видеоэлемтә аша Олимпия чемпионы Камилә Вәлиева да мөрәҗәгать итте. «Татар булуым белән горурланам. Һәрберегезгә ярдәмегез, җылы мөнәсәбәтегез, яхшы сүзләрегез өчен рәхмәт белдерәсем килә. Мин моны тоям һәм миңа бу бик кадерле», – диде ул.

**Белешмә өчен**

«Мәскәү – Татарстан күпере» яшьләр форумы – төрле өлкәләрдә уңышка ирешкән шәхесләр белән яшьләрнең аралашу мәйданчыгы. Форумда Татарстанга бәйле булган яшьләр, шулай ук хәзерге вакытта Мәскәүдә белем алучы һәм эшләүче, илнең башка төбәкләреннән килгән татарлар катнаша. Билгеле булганча, әлеге чараны Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиллеге оештыра.

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН:

# «Авыр чакта ярдәмләшергә кирәк»

**«Бердәм Россия» партиясенең Татарстан бүлегендә узган утырышта Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әнә шулай дип белдерде.**

Аның фикеренчә, илдә барган вазгыять республика халкын тагын да берләштерә. Авыр чакта халыкка, предприятиеләргә ярдәм итү максатыннан «Бердәм Россия»нең Татарстан бүлеге партиянең федераль проектларын тәкъдим итә. Әнә шул рәвешле, Россиягә дустанә булмаган илләрдән кертелгән санкцияләр вакытында илдәге икътисадны тотрыклы итмәкчеләр.

«Бердәм Россия» партиясе 17 федераль проект тәкъдим итә. Алар төрле юнәлешләрне үз эченә ала. Әйтик, араларында «Безнекен сайла», «Шәһәр мохите», «Балалар спорты», «Сәламәт киләчәк», «Ныклы гаилә», «Кече Ватанның мәдәнияте», «Россия авылы», «Эшмәкәрлек», «Яңа мәктәп», «Грамоталы кулланучы мәктәбе», «Хайваннар дөньясын яклау» дигәннәре дә бар.

– Без бүген яңа проектлар тәкъдим иттек. Утырышта шушы проектларның координаторларын һәм иҗтимагый совет рәисләрен сайладык. Илебезгә кертелгән санкцияләр аркасында импортны алыштыруны җайлау өчен дә проектлар барлыкка килде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Соңгы елларда авырлык кичерәбез. Башта коронавирус белән очраштык, хәзер инде тагын кыенлыклар туды. Илдәге вазгыятьне уйлап, яңа проектлар туды. Алар халык өчен дә, сәнәгать һәм җитештерү оешмалары өчен дә файдалы булачак.

Фәрит Мөхәммәтшин, бергәләшеп кенә авырлыктан чыгарга була, ди. Ул моны Луганск, Донецк халык республикалары, Украинага халыкның ярдәм итүен күреп әйтә.

– Татарстанга туган җирләреннән китәргә мәҗбүр булган 1 меңнән артык кеше кайтты. Аларның балаларын бакчага һәм мәктәпкә урнаштырдык. Вакытлыча тору урыннары бар. Ә инде Россиягә кайта алмаганнарына гуманитар ярдәм җибәрдек, – ди Фәрит Мөхәммәтшин. – Аларга «Бердәм Россия» партиясе 95 тонна гуманитар ярдәм озатты. Бу – 6 фура дигән сүз. Көндәлек кирәк-яраклар, азык-төлек җыелмалары янына үз куллары белән оекбаш бәйләп алып килүче кешеләр дә булды. Кабатлап әйтәм: авырлык килгәндә, без Татарстанда яшәүче һәр милләт кешесенең бердәм икәненә тагын бер кат инанабыз.

tatarstan.ru

Утырышта гуманитар ярдәм оештыруга зур өлеш керткән оешма җитәкчеләренә рәхмәт хатлары тапшырылды. Шулай ук «Бердәм Россия»нең районнардагы бүлекләренә сәркатипләр дә сайланып куелды. Фәрит Мөхәммәтшин партиягә яшьләрнең килүенә шат икәнен яшерми.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# Теләгәнгә эш булсын

**Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова Мәшгульлек хезмәте хезмәткәрләре көне белән котлый.**

«19 апрель – кешеләргә тормышта үз урыннарын һәм иртәгәсе көнгә ышаныч табарга ярдәм итүчеләрнең һөнәри бәйрәме. Ел саен халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә меңләгән татарстанлы мөрәҗәгать итә, – диелә котлауда. – Бүген мәшгульлек хезмәте мөһим бурычлары һәм аларны хәл итү өчен мөмкинлекләре җитәрлек булган күпфункцияле структурага әверелде. «Демография» илкүләм проектының «Мәшгульлеккә ярдәм итү» федераль проекты кысасында Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләрен яңарту программасында уңышлы катнаша».

Татарстанның мәшгульлек хезмәтендә 850дән артык белгеч эшли.

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утыз беренче утырышы 21 апрель көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Дәүләт Советы депутатларын теркәү Дәүләт Советы бинасында 21 апрельдә 8.00 сәгатьтән башлап хәл ителә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

# ӨЕҢНӘН ЧЫГАРГА ИРЕНМӘ

**Авыл хуҗалыгы**

**Узган атнада республика язгы кыр эшләренә кереште. Ныклык запасы зур булган мөстәкыйль хуҗалыклар һәм эре инвесторлар да очын очка ялгап барган бер вакытта, фермер хуҗалыклары нинди кыенлыклар кичерә?**

Республика авыл хуҗалыгында җитештерелгән продукциянең 51,3 проценты – крестьян-фермер хуҗалыклары һәм кооперативлар өлеше.

– Дәүләт ярдәменә килгәндә, фермерларга аның нибары 19,7 проценты бирелә. Дәүләт ярдәме күбрәк булса, нәтиҗәсе дә зуррак булыр иде, – ди Татарстан Крестьян-фермер хуҗалыклары берлеге җитәкчесе Камияр Байтимеров.

Авыл хуҗалыгында елның-елы иң югары күрсәткечләр белән эшләүче Саба районы фермерларының да проблемалары санап бетергесез. Алар карамагындагы 3 мең гектардан артык җирне эшкәртеп, ашлап, вакытында чәчү өчен әзерлекләре дә төрле хуҗалыкларда төрлечә. Язгы кыр эшләре өчен кирәк-яракка бәяләр әледән-әле артып торганда, төп кереме игенчелектән булган фермерлар очын очка ничек ялгый алсын? Бер тонна аммиак селитрасы алырга гына да 18900 сум кирәк. Бу кадәр акча булдыру өчен кайбер фермерларга уңышның шактый өлешен сатарга туры килә. Район буенча бер гектарга 60 килограмм тәэсир көченә ия ашлама тупланган булса, фермер хуҗалыкларында ул гектарына 15–20 килограммнан артмый. Билгеле инде, бу кадәр аз күләмдә ашлама кертеп, мул уңыш алып булмый. Фермерлар бүгенгә кадәр үзләренә тиешле субсидияләр бирелмәвеннән зарлана.

– Фермер хуҗалыкларына күпме ашлама кирәк – мәгълүматларны җыеп, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына вакытында тапшырдык. Ташламалы бәядән бер гектарга 20 килограмм исәбеннән ашлама биреләчәк. Ягулык-майлау материаллары, запас частьлар һәм башка кирәк-яракларны алуда да ярдәм күрсәтелә. Күп нәрсә фермерның үзеннән дә тора. Кирәк-яракны арзан чагында – көз көне алып куючылар ота. Хәзер исә бәя икеләтә, өчләтә кыйммәтрәк. Өеннән чыгарга иренгән фермерга беркем китереп бирмәячәк, – ди Саба районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Гафур Хәсәншин.

Фермерлар зарланырга яратмый. Никадәр кыен булса да, яхшыга өмет итеп яшиләр. Спас районы «Киң тормыш» фермер хуҗалыгы җитәкчесе, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Дамир Хәмидуллин да быел мул уңыш булыр дип өметләнә.

«ВТ» архивыннан

– Акча санаганны ярата. Техниканы көздән әзерләп куймасаң, эш-мәшәкате генә түгел, чыгымнары да арта. Запас частьлар, ягулык-майлау материаллары, ашламаны да мөмкин кадәр алданрак булдыру хәстәрен күрдек. Төрле программаларда катнашып, ел саен дәүләт ярдәме алабыз, – ди ул.

Татарстан фермерлары берлеге җитәкчесе Камияр Байтимеров әйтүенчә, республикада фермерлар файдалана алырлык 20 дәүләт программасы эшли. Узган ел дәвамында 1 миллиард 252 миллион сумлык ярдәм күрсәтелгән.

– Быел фермерларга дәүләт ярдәме 100 миллион сумга күбрәк булачак. Тик аны алыр өчен, әлеге дә баягы өеңнән чыгарга иренмәскә кирәк, – ди җитәкче.

Камил СӘГЪДӘТШИН

# БАЛАЛАРНЫҢ ҮЗ ШАГЫЙРЕ

**Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар**

**Татар балалар әдәбияты тарихында гомерен бары тик балалар өчен генә иҗат итүгә багышлаган әдәбиятчыларыбыз күпсанлы түгел. Шөкер ки, алар бар. Шундый чын мәгънәсендә балалар өчен язучы, балалар дөньясын тудыручылардан, балалар әдәбиятына хезмәт итүчеләрдән мин шагыйрь Йолдызны (Йолдыз Шәрәпова) күрсәтер идем. Татар әдәбиятының бик үзенчәлекле бер өлеше булган балалар әдәбиятының соңгы утыз елга якын үсешендә әлеге шагыйрьнең үз сүзе, китап киштәләрендә лаеклы урыны бар.**

Иҗат итүче осталыгы – күптөрле факторлар кушылмасының нәтиҗәсе ул. Аның формалашуына иҗади сәләт һәм тәрбия дә, белем һәм тормыш тәҗрибәсе дә, әйләнә-тирә йогынтысы да – һәммәсе зур роль уйный. Ләкин иң беренче чиратта чын каләм осталарын аларның шәхес булуы аерып тора. Йолдыз исеме белән балаларга таныш булган шагыйрә турында каләмдәшләре фикере кызыклы. Галимҗан Гыйльманов аның турында түбәндәге фикерләрне яза: «Шагыйрәләрнең дә төрлесе була. Кемдер үзен милләт анасы итеп игълан итә, йөрәген иҗтимагый көрәш барган мәйданнарга ташлый, бар көчен, гомерен шунда исраф итә, кемдер, сүзләрдән, образлардан чәчәк ясап, үз шигъриятендә күзләрнең явын алырлык гөлбакча үстерә, ә өченчеләр үзләрен мәхәббәт колы итеп игълан итәләр дә гомерләре буе җир тормышына ят булган илаһи хисләр ялкынында яналар... Тагы бер төрле шагыйрәләр бар. Алар үз каләмнәрен тулысынча сабыйлар мәнфәгатенә, гаилә рухиятенә, балалар тормышы белән бәйле «кызыклы мәшәкатьләр»гә, киләчәк белән бәйле өмет-хыялларга багышлыйлар. Йолдыз – татар әдәбиятында әнә шундый шагыйрәләрнең иң күренеклесе». Замана әдәбиятында үзе дә бик үзенчәлекле интеллектуаль әдәбият үрнәкләре бирүче язучы фикерләре, әлбәттә, шагыйрә Йолдызның үз образын тудыруы белән кыйммәтле.

Балалар шигърияте өлкәсе аның иҗат юнәлешен билгели. Әлеге өлкәдә ул – хәзерге көнгә егермегә якын китап авторы. Иҗат иткән шигырьләренең чуаш, рус, азәрбайҗан, төрек телләренә дә тәрҗемә ителгән булуы шагыйрә иҗатының башка халыкларда да танылуы күрсәткече булып бәяләнергә хаклы.

Шагыйрәнең күп елларга сузылган төп эш урыны «Сабантуй» балалар газетасы булуы күп нәрсә хакында сөйли. Редакциядә беренче еллары бик затлы даирәдә эшләргә мөмкинлек бирә. Ул елларда монда танылган шагыйрьләрдән Йолдызның иҗат кумиры булып торучы Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин эшли, алар кул астында эшләү дәверендә Йолдыз Шәрәпова иҗат тәҗрибәсе туплый, балалар өчен язуның серләренә төшенә. Әлеге язучыларның белем дәрәҗәсе, иҗатка карата мәхәббәте сайланган юлының дөреслеген аңларга ярдәм итә.

1994 елда шагыйрәнең «Антенналы бәрәңге» дип аталган беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә. Әлеге китап укучылар арасында бик тиз тарала һәм китапханәләрдә үз урынын таба, 1994 елда «Ел китабы» конкурсында икенче урынны яулый. Башлангыч чор иҗатына бәя биреп, балалар шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ш. Галиев: «Йолдыз Җамалетдинова шигырьләрен сөенеп укыдым. Карасана, татар баласының табигатен, тәмле телен белеп, тоеп, сабыйның үзедәй ихлас язылган ич! Иплелек, җыйнаклык хас аларга. Кайчакта, тизрәк әйтеп бирергә ашыккан бала сыман, йотлыга-йотлыга сөйләү дә сизелгәли. Бусы да – тулган илһамның юл табып ашкынуыдыр. Балачак күзгесендә олылар дөньясы чагылу, шул гамь-шаянлыктан алып уйчанлыкка кадәр булган кичерешләр шигъри сүзне мәгънәле итә», – дип яза. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, нәшрият мөхәррире, шагыйрь Равил Рахмани да шагыйрәнең иҗатын югары бәяли: «Антенналы бәрәңге» дигән беренче китабының исеменнән үк күренгәнчә, ул авторның бай фантазиясенә, шартлы шигъри фикерләвенә корылган шаян, мавыктыргыч, кызыклы һәм гыйбрәтле шигырьләрен үз эченә ала. Шагыйрәнең күзе үткен, хикмәтле фикерләүгә, юморга күңеле сизгер, бала күңелен, бала табигатен әйбәт белә».

Алга таба да аның иҗаты укытучыларының күз угыннан читтә калмый. «Йолдыз – күңеле белән, фикер йөртүе белән чын балалар шагыйре. Аңа балаларча уйлый белү, моңсулана белү хас. Шуңа күрә дә шигырьләре табигый, балаларның үзләренчә килеп чыга. Ул балалар тормышына хас вакыйгалар, сөйләшүләр, бәхәсләр тудыра. Аның нәни геройлары тапкыр да, шаян да, шул ук вакытта моңсу да. Алар – бернинди ситуациядә дә югалып калмый торган, һәр сорауга җавап таба торган малайлар, кызлар. Алар – гаҗәпләнә, соклана, эзләнә, таба торган тиктормаслар. Аларның әле чын мәгънәсендә беркатлы сабый чаклары», – диде күренекле шагыйрь Роберт Миңнуллин.

Әлбәттә, зур әдәбиятка аяк басу дәверендә үк олы каләм осталарыннан югары бәя, өметләндергеч фикер ишетү үзе – бәхет эшедер! Илһамланып иҗатын дәвам иттерүендә яшь шагыйрәне үсендереп җибәрүче танылган шәхесләребезнең дә өлеше бардыр кебек...

Ни турында гына язса да, Йолдыз гаҗәеп самими һәм ихлас күңелле, үзе шикелле гади укучысының дусты да, теләктәше дә булып кала. Аның шигырьләрендә галилек балачак гадилегенең саф күңел белән генә аңлый ала торган бөеклеге белән аңлатыла.

Шагыйрәнең бер-бер артлы басылып чыккан шигырь китаплары үз исемнәре белән үк, балаларга яңа образлар дөньясы вәгъдә итеп, үзләрен укырга чакырып торалар: «Сәяхәтче чемодан», «Каен алмасы», «Аппак һәм Шапшак», «Антенналы бәрәңге», «Җавапсыз сорау», «Колаклы коймаклар», «Колакчын кигән кояш», «Шигырьле чәй», «Ялкау тел», «Зоопарк-Әлифба» һ.б. Йолдызның зурларга әйтер сүзе дә бар. 2008 елда чыккан «Ярый әле» исемле җыентыгы зурларга аталган шигырьләрдән тора.

saby-rt.ru

Китапның «Балачакны эзлим» шигыре белән ачылуы да аның һаман балачак шагыйре булып калуы турында сөйли. Әлеге җыентыкка кергән «Елгалар һәм диңгезләр» шигыре шагыйрәнең фикерләү рәвешен аңларга ярдәм итә: аның олыгайгач та җанының балаларча самимилеген саклап кала алган сирәкләрнең берсе булуына төшенәсең. Йолдыз Шәрәпованың иҗат дәрьясында алгы планда һәр туган көнгә сөенеп, киләчәккә ышанычлы караш сирпеп, башкаларның күңелләрен канатландырып, шатландырып-куандырып яшәүче, олы җанлы шәхес тора. Әлеге шәхесне, әлеге иҗатны бәяләр, аңлар өчен, укучыга шагыйрәнең вөҗдан, намус, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек кебек мәңгелек төшенчәләр турында язылган әсәрләрен укырга, шуларда күтәрелгән әлеге фикерне үзләштерергә һәм алга таба шул юнәлештә үсәргә кирәк.

Иҗатының башында ук Йолдыз иҗатына балалар әдәбиятының мэтрлары Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин югары бәя бирсә, хәзерге көндә шагыйрә Йолдызны киң әдәби җәмәгатьчелек таныды, иң әһәмиятлесе – балалар үз шагыйре буларак кабул итте. Аның иҗаты мәктәпләрдә әдәбият укыту программаларына, балалар бакчаларының тәрбия эше планнарына кертелде. Бусы – шагыйрә иҗаты өчен иң әһәмиятлесе, дип уйласак, ялгышмабыздыр.

Йолдызлы шагыйрәнең яңа иҗат җимешләре белән сөендерүенә ышанып калабыз.

Флера СӘЙФУЛЛИНА,
КФУ профессоры

**Рәхмәт, табиб!**

# АЗАТ ШӘРИПОВ: «ДӘВАЛАУ ӨЧЕН ЯРАТЫРГА КИРӘК»

**Никадәр генә сакланырга тырышсам да, коронавирус дигән зәхмәт мине дә әйләнеп узмады. Якамнан сөйрәп алып, сырхауханә юлында йөрергә мәҗбүр итте. Температурам 39 градуска җитеп, «ашыгыч ярдәм» бригадасын өйгә чакырырга туры килде. Республика клиник хастаханәсе белгечләре тиешле анализлар алганнан соң, коронавируслы инфекция белән авыруым ачыкланды.**

Югыйсә бу зәхмәткә каршы узган елның июль аенда гына вакцина кадаткан идем. Икенче уколны да табиблар билгеләгән вакытта ясаттым. Кирәк бит: нәкъ менә юбилеема әзерләнеп йөргән көннәрдә шундый куркыныч авыру белән чирләп кит инде...

Табиблар да хәлемә керде бугай. Авыруымның чагыштырмача җиңел формада узуын исәпкә алып, кирәкле дарулар белән өйдә дәваланырга рөхсәт итте. Менә шулай февраль уртасыннан мартның 17сенә кадәр бар вакытым коронавирус белән көрәшеп узды. Әмма бу авыру җиңел генә бирешә торганнардан түгел икән. Хәлем бераз җиңеләйгән сыман була да, бераздан кан басымы күтәрелеп, температура янә кырыкка таба үрмәли. Гомер булмаганны, хәл бетеп азаплый, гел ятып торасы килә. Өстәвенә, кискен хәрәкәт ясасам, баш әйләнеп китә, ниндидер черкиләр очуы күз алдына килә. Ә иң хәтәре – төннәрен һава җитми башлый. Гомер-гомергә йокы вакытын сагынып көтеп алган организм төн җиткәнне куркынып көтсен инде...

Шулай азаплана торгач, көннәрнең берендә янә «ашыгыч ярдәм» чакырмый булмады. Санаулы минутлар эчендә килеп тә җиттеләр. «Ашыгыч ярдәм» дә үзгәргән. Күчмә поликлиниканы хәтерләтә. Тиз арада әллә никадәрле анализлар алып, уколлар ясап, Казанның 12 нче клиник сырхауханәсенә алып киттеләр.

Менә шунда мин кеше сәламәтлеге өчен чын күңелдән җан атып, күңел җылысын кызганмыйча тәүлек дәвамында авыруларга ярдәм итәргә тырышучы табиб Азат Шәриповны очраттым (ул – бүлек җитәкчесе дә). Үзем ята торган 6 кешелек бүлмәдә һәркем янында озак кына тукталып, һәркайсыбызның хәлен җентекләп, бөртекләп сораштыра, дәвалау чаралары билгели, киңәш-табышларын бирә. Башка табиблар, шәфкать туташлары да көн дәвамында әллә ничә тапкыр яныбызга килеп, бүлек җитәкчесенең әйткәннәрен үтәп мәш килә. Өстәвенә УЗИ комплексы аша барлык эчке органнарны, йөрәк һәм кан тамырларындагы тайпылышларны ачыкладылар. Компьютер томографиясе белән – баш миен, спираль компьютер ярдәмендә күкрәк читлегендәге үзгәрешләрне карап, нинди дәва кирәклеген ачыкладылар. Шуның уңай нәтиҗәсе буларак, мин генә түгел, палатадагы башка авырулар да күзгә күренеп савыга алды, дисәм, һич арттыру булмас. Кергәндә сыңар таякка таянып, көч-хәлгә хәрәкәтләнә алган янәшәдәге караватта ятучы 62 яшьлек Николай Иванович, атна ахырына чыгаралар, дип шатланып йөри башлады.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтим әле: чирләп китеп, башка хастаханәләрдә дә ятканым булды. Әмма авыруларга карата бу кадәрле игътибар һәм ихтирам булуын хәтерләмим диярлек. Кирәкле даруларны, хәтта бәдрәф кәгазен дә сырхауханәгә үзең белән алып килергә тиеш булган вакытлар да хәтердә. Ул чактагы табибларны хурлар өчен әйтүем түгел. Арада төрлесе бар иде. Заманча җиһазлары да, дәвасы да азрак, белгечләр дә артык тирәнгә керми генә хәлең бераз җайлангач, тизрәк өеңә озатырга тырыша кебек хәтердә калган. Пандемия дигән куркыныч авыруның тәэсире дә булмый калмагандыр. Кайда-кайда, әмма башкаланың әлеге сырхауханәсендә уңай үзгәрешләр күп булу һәр тарафтан күренә. Табиблар, шул исәптән Азат Шәрипов та үз хастаханәләренә күрсәткән ярдәмнәре, даими игътибары өчен республика җитәкчелегенә, Сәламәтлек саклау министрлыгына рәхмәтле. «Шуның нәтиҗәсе буларак бүген безнең сәламәтлек саклау учреждениесе республиканың иң яхшы хастаханәләреннән санала», – ди табиб.

Бер атна эчендә хәлем яхшырып, хастаханәдән чыккач та, үземне дәвалаган табибларга, аерым алганда, Азат Әхмәт улы Шәриповка, табиб Динар Фәрит улы Фәсхетдиновка, шәфкать туташлары Чулпан, Лилия һәм Вероникага чиксез рәхмәтләремне белдерәсем, изге күңелле табиблар, шәфкать туташларының фидакарь хезмәтләре турында дөньяга белгертәсем килде.

– Чыннан да, 626 кеше эшли торган коллективта үз эшен тирәннән белеп, яратып башкаручы табиблар, шәфкать туташлары, башка күп төрле белгечләр шактый. Азат Шәрипов – шундыйларның берсе, – ди сырхауханәнең баш табибы урынбасары, биредә 40 ел эшләүче Василә Хадеева. – Мин аны студент елларыннан яхшы беләм. Республика клиник хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшләүче тормыш иптәше Алияне, кызлары Алинә белән Әминәне дә. Гаҗәеп тату, үрнәк гаилә. Коронавирус чорында махсус оештырылган госпитальдә айлар буе беркая чыкмыйча, авырулар янында булырга туры килде. Ковид белән авырып киткән 3 меңнән артык кеше безнең госпитальдә дәваланып чыкты. Бүген менә соңгы дүрт кешене өйләренә озаттык.

Шунысы кызык: Шәриповлар нәселендә бердәнбер табиб икән ул. Балачагыннан инженер булырга хыялланып үскән егет ни өчен табиб һөнәрен сайлаган?

– Мин Балтач районы Түнтәр авылында туып-үстем. Әтием хуҗалыкта баш инженер иде. Аның кебек буласым килде. Якыннарым авырып киткәндә ярдәм итәсе килгән чакларым күп булды. Әти-әнинең дә мине табиб итеп күрәселәре килде бугай. Тугызынчы сыйныфта укыганда медицина институтына ныклап әзерләнә башладым. Мәктәпне медаль белән тәмамлап, институтка кердем. Югыйсә абый-апаларымның өчесе дә авылда калды, – дип искә ала Азат Шәрипов.

Хәер, аның авылга кайтуын әле дә көтеп торалар. Гозер белән килгәннәрнең һәркайсына булдыра алганча ярдәм итә. Чыннан да, Ходай аны кешеләрне дәвалау өчен яраткан, күрәсең...

Камил СӘГЪДӘТШИН

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында**

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм**:

1. Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указы нигезендә сигез яшьтән алып унҗиде яшькә кадәрге балалар өчен 2022 елның 1 апреленнән билгеләнгән айлык акчалата түләүне (алга таба тиешенчә – айлык түләү, Россия Федерациясе Президенты Указы) башкару буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен Россия Федерациясе Пенсия фондына тапшырырга.

2. Айлык түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «8 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалар өчен айлык акчалата түләүне башкару тәртибенә һәм шартларына төп таләпләрне, әлеге айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) үрнәк исемлеген һәм аны билгеләү турында гаризаның үрнәк формасын раслау хакында» 2022 елның 9 апрелендәге 630 номерлы карарында (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Указның 1 пункты нигезендә тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен үтәү өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына субвенция бирү турында Россия Федерациясе Пенсия фонды белән килешү төзергә;

2022 елның 1 маена кадәр гражданнарның Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре яисә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша айлык түләүләрне билгеләүне сорап, шул исәптән гражданнардан дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларның эш документлары булып торган документларны таләп итмичә, мөрәҗәгать итә алуын тәэмин итәргә;

2022 елдан башлап ел саен Россия Федерациясе Президенты Указын гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауга Россия Федерациясе субъектларының чыгымнар буенча йөкләмәләрен уртак финанслау күләмен исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләрне формалаштыру, аларны бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә айлык түләүләрне башкаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирүне күздә тотарга;

Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын һәм әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 16 апрель, № ПУ-285

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын нygытуга зур өлеш кертүе өчен хезмәт ветераны **Хаҗиәхмәтова** Валентина Серафимовна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринария табибы **Мөкасиева** Рамилә Гакыйф кызына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор А.Г. Ге исемендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Әлмәт тире-венерология диспансеры» филиалы баш табибы **Батрасов** Юрий Юрьевичка, «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиб-хирургы **Русов** Алексей Валерьяновичка, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Сәгъдиев** Айдар Рөстәм улына, «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы – стоматолог-терапевты **Фазлыева** Алсу Рәшит кызына, «Минзәлә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең участок табиб-педиатры **Шестакова** Гүзәлия Шамил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ЭР-Телеком Холдинг» акционерлык җәмгыятенең b2g проектлары, Казан шәһәрендәге филиалының b2g сату төркеме җитәкчесе **Горнаев** Дмитрий Владиславовичка, «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятенең коммутация челтәрләре үзәге башлыгы **Чернов** Юрий Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Гидросервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бульдозер машинисты **Буланов** Иван Анатолевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Буревестник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе **Трошанин** Владислав Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

## КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, Чаллы шәһәре Үзәк районы башлыгы **Галимов Искәндәр Нургаләм улы**ның кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

**Белдерү**

**Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границ земельного участка**

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом Саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:100308:27, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Московский район, ГСК «Восход», участок 14, проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Климанова Наталья Владимировна (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 89030618183).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 19 мая 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63 с 19.04.2022 г. по 19.05.2022 г.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ земельных участков с кадастровыми номерами:

16:50:100308:26, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Московский район, ГСК «Восход», участок 13;

16:50:100308:52, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Московский район, ГСК «Минутка», участок 17;

16:50:100308:1, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Московский район, ГСК «Восход», участок 15.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Хәзинә

vk.com/millihasite

# *Моңлы сурәтләр*

**Татар милли киеменең бөтен матурлыгын, нәзакәтен пумала белән киндергә сурәт төшереп кенә җиткереп буламы? Ул алынса, була икән. Татар хатын-кызының кабатланмас йөз чалымнарын да үзенә генә хас төгәллек белән сурәтли Әнвәр Сәйфетдинов.**

Татарстанның Рәссамнар берлеге әгъзасы, «Дастан» арт-төркеменә нигез салучы останың «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә үзенчәлекле күргәзмәсе ачылды. Әлеге күргәзмә татар костюмнарын торгызу эшен башкара торган Millihasite проекты белән берлектә иҗат ителгән картиналар сериясеннән гыйбарәт. «Мин гомерем буе татар халкының XIX гасырга караган искиткеч костюмнарын үз сурәтләремдә чагылдыру турында хыялландым», – ди рәссам үзе.

Картиналарда сурәтләнгән костюмнарны Millihasite дизайнерлары теккән. Надежда Шәйхисламова сүзләренчә, татар костюмы элементларга гаять бай. «Бу коллекциягә караган киемнәрне исә XIX гасырда яшәгән бай хатын-кызлар тектергән була. Шуңа да аларның тукымалары бик сыйфатлы, еракта кайтартылган булса кирәк. Костюмнарга кыйммәтле ташларны да кызганмаганнар. Моннан тыш, костюмнар хатын-кызның яшенә карап та аерылган», – диде ул, костюмнар белән таныштырып. Надежда ханым мондый күргәзмәләрнең башка беркайда булмавына да басым ясады. «Биредә картиналар белән генә түгел, шул картиналарда сурәтләнгән образлар белән дә танышып була, төп үзенчәлеге шул», – диде ул.

Шушы костюмнарның матурлыгын, байлыгын, үзенчәлекләрен түкми-чәчми сурәтләгән Әнвәр Сәйфетдинов татар халык киемнәрендә бәһасез байлык тапкан. «Мин бу эшемне дәвам иттерергә телим, чөнки үземнән соң мәдәни капитал калдырасым килә. Әгәр бүген тәкъдим ителгән картиналарга озаграк карап торсагыз, андагы детальләрнең күплегенә шаккатачаксыз. Татар костюмы шул ягы белән үзенчәлекле ул. Аларны сурәткә төшерү бер дә җиңел булмады», – ди ул.

Әнвәр Сәйфетдинов үз әсәрләрендә татар халкының табигать, җир белән элемтәсенә игътибар итә. Бу күргәзмәдә тәкъдим ителгән картиналарда да татар халык киемнәрендә табигатьтәге бизәкләрнең чагылыш табуын күрергә мөмкин. Алай гына да түгел, картиналарга карауга, нинди фасыл, көннең нинди вакыты сурәтләнүен дә шундук аңларга була.

Күргәзмәне Татарстанның Рәссамнар берлеге рәисе Альберт Шиабиев та югары бәяләде. «Әнвәрнең Татарстанның рәсем сәнгатенә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Бүгенге күргәзмә моны кабат раслады», – диде ул.

Танылган сәнгать белгече Розалина Шаһиева исә Әнвәр әфәнденең сурәтләрен «моңлы» дип атады: «Без, гадәттә, бу төшенчәне җыр сәнгатенә карата кулланабыз, татар халык җырларының кабатланмас моңы бар, дибез. Ә менә Әнвәр шушы моңны картиналарында да сурәтли алган. Әйе, могҗиза бу!»

Лилия ГЫЙМАЗОВА

## Чемпионнар бишегенә – 99!

**«Динамо» спорт җәмгыяте зур юбилеена әзерләнә. Шул уңайдан «Татар-информ»да матбугат очрашуы узды.**

– Бүген минем «Динамо»ны бөек җәмгыять дип атарга сәбәпләрем җитәрлек. Хәер, ул моны, дөньядагы иң яхшы спорт җәмгыяте буларак танылып, узган гасырда ук раслады. Нәкъ бер елдан без «Динамо» оешуның 100 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Бер гасырлык тарих дигән сүз бит бу! – дип сөйләде Татарстанның «Динамо» спорт җәмгыяте рәисенең беренче урынбасары Салават Гайсин.

Россиянең синхрон йөзү буенча федерациясе вице-президенты Ольга Павлова исә бөтен тормышының «Динамо»га бәйле булуын әйтте.

– Бүгенге уңышларымда әлеге җәмгыятьнең өлеше бик зур. Минем өчен «Динамо» ул – спорт кына түгел, социаль гарантияләр дә. Чөнки «Динамо» балаларга, һәлак булган хәрбиләрнең гаиләләренә, ветераннарга һәрдаим ярдәм күрсәтә, – диде ул. – Татарстанның «Динамо» җәмгыяте тарихында аның бүгенге рәисе – Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров якты эз калдырачак. Сер түгел, ул авыр чорларда күп кенә командалар һәм тренерларга зур ярдәм күрсәтте. Гомумән, спортчылар өчен яңа чор башланды дияргә була. Спортта хәрәкәт тизлеген югалтырга ярамый. Мин дә «Динамо»га шуны телим.

Моннан 21 ел элек Әрмәнстаннан Татарстанга килеп, шуннан бирле чирәмдәге хоккей буенча «Динамо-Казан» ирләр җыелма командасының баш тренеры булган Араик Маргарян, «Динамо» җәмгыяте спортчыларны гына түгел, тренерларны да тәрбияли, дигән фикердә.

– Спортның нәрсә икәнен төгәл белә торган җәмгыятьтә эшләү – зур уңыш ул. Тренерларга бит команда вәкилләренең генә түгел, җитәкчеләрнең дә аңлый белүе мөһим. Монда килеп, алты ай эшләгәннән соң, без Россия кубогы оттык. Шуннан соң Әсгать Әхмәт улы белән очраштык. Шул очрашуда ук, мине монда аңлыйлар һәм аңлаячаклар, дигән нәтиҗәгә килдем, – дип сөйләде ул матбугат очрашуында. – Бүген дә безнең һәр җиңүебезне тиешле дәрәҗәдә бәяли беләләр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның спортчыларны уңышлары белән шәхсән котлавы да зур әһәмияткә ия. Чөнки бу – спортчылар өчен командага тагын да зур җиңүләр китерергә зур стимул, этәргеч.

Россиянең атказанган спорт мастеры, Токиодагы Олимпия уеннарының көмеш медаль иясе Александр Красных та «Динамо» җәмгыятенең бер өлеше булуы белән горурлануы турында әйтте.

**«ДИНАМО» – ФАКТЛАРДА**

✓ Көч оешмалары хезмәткәрләрен берләштерү һәм аларның көчен спорт мәйданчыгында сынау идеясе Феликс Дзержинскийныкы булган.
✓ Җәмгыятьнең исемен Максим Горький уйлап тапкан. Ул «Хәрәкәттә – көч» дигәнне аңлата икән.
✓ Татарстанда «Динамо» җәмгыяте 1926 елның 29 гыйнварында оеша.
✓ Бүген «Динамо» составына барлыгы 25 мең кешедән торган 26 коллектив керә.

# ФИКЕР ТӨРЛЕ, МАКСАТ БЕР

Президент программасы

**Республикада 2023 елда төзекләндереләчәк җәмәгать урыннары һәм ишегаллары өчен тавыш бирү башланды. Быел Татарстанда 1200 ишегалды төзекләндереләчәк. Моның өчен 9 млрд сум акча тотылачак. Әлеге эшләр «Безнең ишегалды» программасы буенча башкарыла. Исегезгә төшерәбез: бу программа, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме буенча, 2020 елда эшли башлады.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Татарстан шәһәрләре үсеше институты» фонды директоры урынбасары, «Безнең ишегалды» программасы координаторы Венера Камалова сүзләренчә, әлеге программа халык фикере нигезендә тормышка ашырыла.

– Елдан-ел әлеге программаны халык үз итә. 2020 елда ишегалларын төзекләндерүгә карата 300 мең кеше фикерен җиткерсә, хәзер аларның саны 2 миллионга җитә, – ди ул.

Белгечләрнең халык белән очрашуында «ВТ» журналисты да катнашты. Берничә көн элек Казанның «Сәйдәш» мәдәният йортына Совет районында ишегаллары төзекләндереләчәк кешеләрне җыйганнар иде. Халыкның район җитәкчесе, программа координаторы Венера Камалова, архитектор белән аралашуы бик җанлы узды. Залда утыручыларның сораулары күп җыелган иде. Аеруча Сеченов урамында яшәүчеләр иза чигә икән. Янәшәләрендә генә урнашкан хастаханәләргә йөрүче машиналар еш кына куркыныч тудыра, дигән дәгъваларын җиткерде алар.

– Бездә балалар мәйданчыгы да юк. Урамда баланы уйнатам, димә. Машиналар тыз-быз йөреп тора. Әле кайчак, бөкедә утырмас өчен, ишегалдыннан урап узалар. Безнең бер генә теләк: шлагбаум куегыз, – ди Мәдинә Лотфуллина.

Аның сүзен куәтләүчеләр шактый булды. Араларында чәчәкләр үстерүне сораучылар бар иде. «Бер машина туфрак китерсәләр, чәчәкләрне үзем үстерәм», – диючесе дә табылды. Ә менә Новаторлар урамында яшәүче абзый очрашуга доклад әзерләп килгән иде. Шулай ук корыган агачларны кисеп ташлауны сораучылар да, аларга каршы төшүчеләр дә табылды. Ишегалларыннан үтеп, тимер юлга чыгучылар өчен дә юлны япмакчы булалар. Ландыш исемле ханым йортлары янынннан шаурма ясаучы киоскны алуны сорый. Кыскасы, халыкның тәкъдимнәре дә, зарлары да җитәрлек булды. Машина кую урыны җитмәгән, юллары искергән ишегаллары да шактый. Ә «Безнең ишегалды» программасы буенча башкарасы эшләр исемлегендә болар бар.

Шунысын искәртик: бу программада 2014 елга кадәр төзелгән йорт ишегаллары катнаша ала. Әмма бер шарты бар: моңарчы аларда бернинди төзекләндерү эшләре үтмәгән булу кирәк. Программага йортка илтүче юлларны һәм тротуарларны төзекләндерү, утыргычлар, чүп савытларын яңарту, урам баганаларындагы утларны алыштыру, кирәк урында яктырткычлар кую, балалар мәйданчыгы булдыру, спорт җиһазлары урнаштыру, чүп ташлау өчен мәйданнар булдыру, кер элү һәм кагу өчен махсус урыннар ясау керә.

Халык мондый очрашуны көткән икән. Сөйләшү тәмамлангач та, таралышырга ашыкмадылар. Һәр кешенең үз соравы бар. Венера Камалова әйтүенчә, халык белән уртак фикергә килү авыр булачак.

– Бер йортта яшәгән кешеләрнең дә фикерләре төрле. Алар уртак фикергә килә алмый. Әмма без һәркайсына да ярарга тырышачакбыз. Алар – безне, без аларны аңларбыз дип ышанам, – ди ул.

Үз фикереңне онлайн рәвештә дә белдереп була. 15 апрельдән 30 майга кадәр теләгән һәр кеше 2023 елда яңартылачак парк һәм скверлар, ишегаллары өчен тавыш бирә ала. Сораштыруда 204 җәмәгать урыны, 3087 ишегалды катнашачак. Шунысы да бар: аларның 200ен халык үзе сайлап алачак. Моның өчен Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлергә кирәк. Сораштыру һәр кешенең шәхси битенә җибәрелә. Иң элек җәмәгать урыннары хакында сораулар булачак. Аңа җавап биреп бетергәч, ишегаллары темасына күчеп була. Үзеңә кирәклесен сайлап, тавыш бирәсең. Бер кеше бары тик бер урын өчен генә үз фикерен калдыра ала. Ә инде сезнең ишегалды ул исемлеккә кергәнме-юкмы икәнне dvor.tatar. сайтыннан яки 8 (800) 275-2020 телефонына шалтыратып белешергә мөмкин.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

**Сан**

**2015** елдан Татарстанда **350**дән артык җәмәгать урыны төзекләндерелгән. **2020** елдан «Безнең ишегалды» программасы кысасында **7** мең ишегалды яңартылган.

# АВЫЛ КУЛИБИНЫ

Оста

**Арча районының Иске Кырлай авылында яшәүче Данил абый Әхмәтҗановны «уйлап табучы» дип йөртәләр. Кая гына эшкә урнашса да, кул хезмәтен җиңеләйтү өчен, төрле агрегатлар ясый ул. Өендәге кабак, кырлыган (иван чәй) турагыч, иттарткыч, мамык ясаучы җайланма да – аның хезмәте. Техник белеме булмаса да, башына килгән идеяне тормышка ашырмыйча калганы юк әле.**

Үрнәк училищесында тракторчы-слесарь белгечлегенә укыган егеткә кайларда гына эшләргә туры килмәгән. Башта авылда 15 еллап техника иярләгән. Колхоз бетеп, җирләрне инвестор алгач, склад мөдире эшенә күчкән. Аннан Наласа якларында – инженер, «Кырлай» агрофирмасында – бәрәңге үстерүче. Эшсез торган чагында авыл халкының машиналарын ремонтлаган. Бүген Иске Иябаш авылында рапс мае заводында эшли.

– Техникага кечкенәдән үк тартылдым. Мәктәптә укыганда, тракторчы Нургали абый янында кайнаштым. Мине әле ачкыч, әле шөреп артыннан йөгертә иде. Аннан үзем дә трактор йөртергә өйрәндем, – ди Данил Әхмәтҗанов.

Авыл хуҗалыгы тармагында эшләгәч, авыр хезмәтне җиңеләйтү турында уйлаган вакытлары аз булмый аның. Шул ук вакытта терлекләргә дә файдасы булсын дип тырыша. Иске Иябаш авылы амбарында эшләгәндә, бозауларга арпа, солыны издереп ашата торган станок ясый. «Изелмәгән солы ашказанында эшкәртелеп бетми, ә бу җайланма ярдәмендә күпме бозауларны көр итеп үстердек, – ди ул беренче хезмәт җимеше турында. – Тагын бер станогым чи ашлыкны пешереп чыгара иде. Температура хәттә 150 градуска кадәр җитә. Берзаман рапс маен ягулыкка кушып куллану турында сүз чыкты. Әлеге культураның түбен хайваннарга ашаталар, ә маен тапшыра алмыйча, кая куярга белмиләр. Түгәсе килми, әрәм була бит. Менә шул вакытта маен чистарту өчен махсус җайланма эшләдем. Майны ягулыкка куша идек. Идеяләр уйламаганда туа. Колхозда кәбестә утырттык. Уңышын машинага ыргыту уңайсыз иде. Аны җыя торган транспортер булдырдык.

Эштә генә түгел, Данил абый – гаилә тормышына да җиңеллек өстәүче. «Инстаграм»да «Авыл апасы» буларак танылган блогер Фәйрүзә Әхмәтҗанованың ире булып чыкты ул. Блогерның төрле үләннәр җыярга әвәс икәнен беләбез. Ул йә күркә вареньесы ясый, йә урманнан кырлыган җыя. Чын табигать баласы. Кочак-кочак үлән күтәреп кайтуына ире дә күз йома алмый. Әнә бер елны күп итеп иван-чәй җыеп кайткан. «Бөтен дөньяның кырлыган дип шаулаган чагы. Янәсе, чәй бик күп төрле авырудан дәва. Фәйрүзә аны пычак белән дә турап карады, иттарткычтан да чыгара алмыйча азапланды. Шулвакыт әлеге чәй әзерләү өчен турагыч ясап бирдем. Аны алып кайтабыз да, яфрагын юып, гранула кебек чыгарабыз. Өстенә әйбер бастырып торабыз, аннан киптерәбез», – ди булдыклы ир.

Узган ел кабак уңган. Биш сутыйдан бер «ГАЗель» машинасы уңыш алганнар. Моның кадәр кабакны нишләтеп бетерергә кирәк?! Мал-туарга турап ашатсаң, кулың калмас. Аптырагач, Данил абый кабак турагыч ясаган. Кабакны күз ачып йомганчы ваклап бирә икән. Әле бу көннәрдә гаилә башлыгы гадәти иттарткычны электрга көйләп үзгәрткән. Анысын да сарайга урнаштырган. Дөрес, әле ит чыгарып карамаганнар. Әмма файдасы тияр дип өметләнәләр.

Оныкларын да сөендерә белә торган бабай булып чыкты әле ул. Шәһәрдән кайтучы оныкларын баллы мамык белән сыйлый. Кибеттән сатып алып түгел, үзе әзерләп. Җайланма өчен пластмасса табак, газ баллоны һәм вак-төяк детальләр кирәк булган. Бер уч шикәр комыннан зур мамык чыга. Оныклары кайтыр алдыннан тизрәк станокны кабыза. Кыскасы, балалар мәхәббәтен яулый белә. Идея ничек башына килгәнен үзе дә әйтә алмый, тик сабыйларны сөендерү теләге көчле булган, күрәсең.

Гомумән, җайланма өчен кул астында булган тимер-томырдан файдалана. Электр моторы, газ баллоны… Башка кирәк-яракны сатып ала.

– Идея ничек туа соң? – дип сорыйбыз кулибиннан.

– Авыл җирендә хәзер әллә ни эш юк бит. Кышын мал карап кергәч, буш вакыт күп. Диванда телевизор карап ятып кына булмый. Менә шул чакта нәрсәдер майтарып куям. Вакытны уздыру өчен бик әйбәт. Хыялланып утырган юк, кайчак интернеттан караштыргалыйм. Теләк булса, барын да эшләргә мөмкин. Мәктәптә физиканы өйрәнүнең дә файдасы тия, – ди Данил Әхмәтҗанов.

Кушаматлары «котыр» икән. Юлга кузгалганда, Фәйрүзә апа шулай дип пышылдады. Нәселләре бик тырыш аларның, котырып эшлиләр дип мактады. Бәлкем, Данил абыйда идеяләр дә шундый каударланган чакта туадыр. Чиратта – нинди техника? Монысын тормыш үзе күрсәтер. Нәрсә кирәк, шуны җәһәт кенә ясап бирер. Иренми бит ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 255

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+